**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3755**
**10.05.2023**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы Карары белән расланган Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны тәэмин итү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2023 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2023 елның 21 мартындагы 206/пр номерлы Приказы, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» КП экспертиза-консультация советы тарафыннан үткәрелгән тикшеренү нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яшь гаиләләргә торак урыннар сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2023 елның икенче кварталына 74 312 сум күләмендә билгеләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов